КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1082

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасын раслау турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1056 нчы карары белән расланган 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасын раслау турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1056 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 июль, 548 нче; 2015 ел, 26 май, 378 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1024 нче һәм 2016 ел, 30 сентябрь, 697 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау күләме 3 898, млн.сум тәшкил итә, шул исәптән федераль бюджет акчасы исәбеннән – 1 819,2 млн.сум; Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 1 943,3 млн.сум; бюджеттан тыш чыганаклардан – 135,8 млн.сум.<br>(млн.сум) |

| Ел | Програм-ма буенча финанслау | Татарстан Республи касы | Россия Федерация се бюджет | Җирле бюджет-лар | Бюджеттан тыш чыганак- |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | күләме барлыгы | бюджеты акчасы | акчасы | акчасы | лардан акча |
| | 2013 | | | | | |
| | 2014 | 46,2 | 9,9 | 36,3 | | |
| | 2015 | 136,4 | 84,6 | 51,8 | | |
| | 2016 | 1203,5 | 625,2 | 442,5 | | 135,8 |
| | 2017 | 1708,4 | 821,4 | 887,0 | | |
| | 2018 | 803,8 | 402,2 | 401,6 | | |
| | Барлы-гы | 3898,3 | 1943,3 | 1819,2 | | 135,8»; |

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «III. ПРОГРАММАНЫҢ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕН НИГЕЗЛӘҮ

Программаны финанслау күләме 3 898,3 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән федераль бюджет акчасы исәбеннән – 1 819,2 млн.сум; Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 1 943,3 млн.сум; бюджеттан тыш чыганаклардан – 135,8 млн.сум.

(млн.сум)

| Ел | Программа буенча финанслау күләме барлыгы | Татарстан Республика-сы бюджеты акчасы | Россия Федерациясе бюджеты акчасы | Җирле бюджет-лар акчасы | Бюджеттан тыш чыганак-лардан акча |
|---|---|---|---|---|---|
| 2013 | | | | | |
| 2014 | 46,2 | 9,9 | 36,3 | | |
| 2015 | 136,4 | 84,6 | 51,8 | | |
| 2016 | 1203,5 | 625,2 | 442,5 | | 135,8 |
| 2017 | 1708,4 | 821,4 | 887,0 | | |
| 2018 | 803,8 | 402,2 | 401,6 | | |
| Барлыгы | 3898,3 | 1943,3 | 1819,2 | | 135,8 |

Программаны ресурслар белән тәэмин итү фаразы Программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.»;

Программага 1 нче кушымтаны әлеге карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин